**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге**
**Советы**

422740, Әтнә муниципаль районы
Күәм авылы,Х.Такташ урамы, 1/1
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Кубянского сельского поселения**

422740, Атнинский муниципальный район
с.Кубян, ул. Х.Такташа, 1/1
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 октябрь 2024 ел. № 7

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге Үртәм торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2024 елнын 1 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенә керүче Үртәм торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Үртәм торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитеты;

-гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2024 елның 1 ноябре 10.00 сәгатькә;

-үткәрү урыны – Үртәм авылы, Дуслык ур., 32 номерлы йорт яны;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 25 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күәм авылы, Х.Такташ урамы, 1 йорт,1003 б.;

- сайлау хокукына ия булган Үртәм торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;

- гражданнар җыены турында Үртәм торак пункты халкына мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

1.3. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2025 елда Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Үртәм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләр, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үртәм авылындагы урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү өчен вак таш сатып алу, хезмәтләр өчен түләү).

"РИЗА" "КАРШЫ"

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Үртәм авылы Дуслык урамы 32 нче йорт адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күәм авыл җирлеге башлыгы: Хасбиуллин И.И.